“Яшелчә бакчасында”.

Матур, аяз көзге көн. Киртә белән әйләндереп алынган яшелчә бакчасы. Анда төрле-төрле яшелчәләр үсеп утыра. (Яшелчәләр булып киенгән балалар көчкенә урындыкларда утыралар.) Бакчаның җилкапкасыннан бер кыз бала килеп керә. Ул кулына буш кәрзин тоткан. Кыз, җырлый-җырлый, бакча уртасына таба үтә.

Кыз: Исәнме, Бакчакай,
Көттеңме син мине?
Әнием җибәрде,
Күреп кайт, дип, сине.
Белеп кайт, - диде ул.
- Яшелчәләр җыеп
Алып кайт, - диде ул.
(кинәт сокланып туктап кала):
Абау, нинди генә яшелчәләр юк икән монда!

Кыз кәбестә булып киенгән бала янына килеп баса, аңа сокланып елмая.

Кәбестә: Мин булам – Кәбестә.
Үзем яшькелт төстә,
Күлмәгем күп катлы,
Үзем бик тә татлы...
Ашларга да төшәм мин,
Бәлештә дә пешәм мин.
Чөнки мине балалар,
Көн де көтеп алалар.

Кыз: Бик әйбәт. Рәхмәт сиңа. Мин сине алырмын, кәрзинемә салырмын.

Суган булып киенгән бала янына килә.

Суган: Минем исемем – Суган,
Мин Һиндстана туган.
Мине бик тә мактыйлар,
Шифалы дип атыйлар.
Салатка да турыйлар,
Тураганда елыйлар.

Кыз: Бик әйбәт. Рәхмәт сиңа. Мин сине алырмын, кәрзинемә салырмын.

Кишер: Минем исемем – Кишер.
Теләсәң, болай пешер,
Теләсәң, ашка тура.
Мине яраткан бала
Озын гомерле була...

Кыз: Бик әйбәт. Рәхмәт сиңа. Мин сине алырмын, кәрзинемә салырмын.

Кәҗә: Яратам Кишерен дә,
Яратам Суганын да,
Кәбестәсен, Борчагын –
Яратам мин барын да.
Мә-мәә! Барыгыз да үземә-әә..
Берегезне дә бирмим.
Кызны сөзеп егам да
Сезне ашап бетерәм!.. Мә-әә!..

Яшелчәләрне куып йөри башлый. Яшелчәләр, куркышып елый-елый, төрле якка качалар. Кыз, йөгереп барып, озын чыбык сындырып ала.

Кыз: Еламагыз, туктагыз,
Бернидән курыкмагыз,
Кәҗә бакчага кергән –
Чыбык татыйсы килгән!
Менә сиңа! Менә сиңа!!! *(Кәҗәне куа.)*

Чыбык белән яный-яный, Кәҗәне куып җибәрә. Яшелчәләр, куанышып, Кыз янына җиелалар.

Яшелчәләр *(барысы бергә)*
Кишер: Үскән кыз да икәнсең,
Матур кыз да икәнсең.
Суган: Матур гына да түгел,
Батыр кыз да икәнсең.
Кәбестә: Кәҗәгә каршы бардың,
Безне коткарып калдың.
Бергә: Рәхмәт сиңа, мең рәхмәт,
Үзең дә яшә рәхәт.